**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 11 июнь № 398

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә төбәк әһәмиятендәге комплексны юнәлешле А.И.Щеповских исемендәге «Степной» дәүләт табигать тыюлыгын оештыру турында» 2000 ел, 26 октябрь, 744 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 май, 349 нчы; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган А.И.Щеповских исемендәге Төбәк әһәмиятендәге комплексны юнәлешле «Степной» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктка «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә;

1.5 пункт үз көчен югалтуын танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ландшафт юнәлешендә төбәк әһәмиятендәге «Балтач» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 6 август, 360 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 10 июнь, 259 нчы; 2010 ел, 19 апрель, 276 нчы; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2015 ел, 16 февраль, 92 нче; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Комплексны юнәлешле төбәк әһәмиятендәге «Балтач» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктка «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә;

8 пункт үз көчен югалтуын танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ландшафт юнәлешендә төбәк әһәмиятендәге «Чулпан» дәүләт табигать тыюлыгы турында нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 19 август, 379 нчы карары белән (Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 13 май, 359 нчы; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Ландшафт юнәлешендә төбәк әһәмиятендәге «Чулпан» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктка «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә;

5 пункт үз көчен югалтуын танырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Долгая Поляна» тарих-архитектура һәм табигать паркын төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле «Долгая Поляна» дәүләт табигать тыюлыгы итеп үзгәртеп оештыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тәтеш районы территориясендә «Долгая Поляна» тарих-архитектура һәм табигать паркын төзү турында» 2000 ел, 7 июль, 486 нчы карары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2004 ел, 3 ноябрь, 471 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 18 июль, 352 нче; 2010 ел, 22 апрель, 292 нче; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 май, 349 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле «Долгая Поляна» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктка «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә;

7 пункт үз көчен югалтуын танырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 14 гыйнвар, 1 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 25 июль, 365 нче; 2009 ел, 19 июнь, 406 нчы; 2010 ел, 12 апрель, 256 нчы; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 май, 349 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 637 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

беренче абзацка «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә;

өченче абзац үз көчен югалтуын танырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге комплекс юнәлешендәге «Ашыт» дәүләт табигый тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 20 июнь, 295 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 май, 349 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге комплекс юнәлешендәге «Ашыт» дәүләт табигый тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

беренче абзацка «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә;

өченче абзац үз көчен югалтуын танырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чатыр Тау» комплекслы юнәлештәге дәүләт табигый тыюлыгын оештыру турында» 2005 ел, 18 июль, 353 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 май, 349 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Чатыр Тау» комплекслы юнәлештәге дәүләт табигый тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

беренче абзацка «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә;

өченче абзац үз көчен югалтуын танырга.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге «Кичке Таң» комплекслы юнәлештәге дәүләт табигый тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 18 июль, 360 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 11 ноябрь, 891 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 май, 349 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге «Кичке Таң» комплекслы юнәлештәге дәүләт табигый тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 пунктның беренче абзацына «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы юнәлештәге «Чистые луга» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 31 октябрь, 513 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 май, 349 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Комплекслы юнәлештәге «Чистые луга» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

беренче абзацка «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә;

өченче абзац үз көчен югалтуын танырга.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы юнәлештәге «Спасский» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 23 ноябрь, 549 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 май, 349 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Комплекслы юнәлештәге

«Спасский» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

беренче абзацка «, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган» сүзләрен өстәргә;

өченче абзац үз көчен югалтуын танырга.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле «Зөя буйлары» дәүләт табигать тыюлыгын оештыру турында» 2008 ел, 14 апрель, 221 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлешле «Зөя буйлары» дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Тыюлыкка йөкләнгән вазыйфалар нигезендә функцияләрне гамәлгә ашыру өчен, шулай ук тыюлык эшчәнлеге белән идарә итү максатларында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының структур бүлекчәсе булган «Зөя буйлары» ДТКТ администрациясе төзелә (алга таба – тыюлык администрациясе).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков